КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 ноябрь г.Казань № 1013

Креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү өчен югары белем бирү мәгариф оешмасына субсидия рәвешендә грант бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү өчен югары белем бирү мәгариф оешмасына субсидия рәвешендә грант бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 15 ноябрь, 1013 нче карары белән расланды

Креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү өчен югары белем бирү мәгариф оешмасына субсидия рәвешендә грант бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү өчен югары белем бирү мәгариф оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант (алга таба – грант) бирү механизмын, максатын һәм шартларын билгели.

2. Грант бирү максаты – креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

3. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак грант бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

Грант турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы

тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

4. Грант әлеге Тәртипнең 2 пункты белән билгеләнгән максат өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә оешмага бирелә.

5. Сайлап алуны үткәрү ысулы – әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән сайлап алу критерийларына оешманың туры килүеннән һәм сайлап алуда катнашуга заявкалар (алга таба – заявка) керү чиратыннан чыгып, оешмалар тарафыннан сайлап алуда катнашуга җибәрелгән заявкалар нигезендә тәкъдимнәр соратып алу.

6. Грант алучыны сайлап алу критерийлары:

заявка бирү көненә оешманың креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү тәҗрибәсе кимендә өч ел булу;

оешма Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган датага кадәр кимендә өч ел Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

оешманы гамәлгә куючы – Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы;

заявка бирү датасына оешманың креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру карала торган алты елга эшчәнлек планы булу.

7. Заявка бирелгән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага оешма туры килергә тиешле таләпләр:

оешма чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

оешма экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

оешма БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру

кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

оешма Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

оешма «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

оешманың бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмау;

оешманың башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

оешма үзгәртеп оештыру (оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, оешманың эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки оешманың баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмау;

8. Сайлап алуда катнашу өчен оешма Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

үз эченә шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә оешма турындагы, оешма бирә торган заявка турындагы мәгълүматны, тиешле сайлап алуга бәйле булган оешма турындагы башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын ала торган һәм әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән формада булган заявка;

оешманың гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелгән барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләре;

оешмага карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органының (дәүләт органының) оешманың сайлап алуда катнашуына ризалыгы;

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазе күчермәсе;

җитәкче яисә оешма исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат һәм оешманың баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган, оешманың әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы икенче, өченче һәм алтынчы абзацларында билгеләнгән критерийларга туры килүен раслый торган мәгълүмати хат;

җитәкче яисә оешма исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат һәм оешманың баш

бухгалтеры тарафыннан имзаланган, әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә оешманың туры килүен раслый торган мәгълүмати белешмә кәгазе;

салым органының салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычы башкарылу турында белешмә кәгазе.

Әгәр оешма тарафыннан әлеге пунктның бишенче һәм сигезенче абзацларында каралган документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә ала.

Оешма оешма җитәкчесе тарафыннан үз кулы имза куелган кәгазь чыганакта заявка булдыра һәм аны сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән срокларда турыдан-туры Министрлыкка яисә почта аша бирә.

Оешма тарафыннан заявканың тапшырылу датасы итеп аның Министрлыкның урнашу урыны буенча почта бүлегенә керү датасы яисә Министрлыкка турыдан-туры заявка керү датасы санала.

Электрон формада файдалану мөмкинлеге булган, заявкага кертелә торган документлар һәм материаллар күчермәсендә мәгълүматны карау өчен билгеләнгән һәркем файдалана алырлык программа тәэминаты белән документны тулысынча яки аның бер өлешен карау мөмкинлеге тәэмин ителә торган, киң таралган ачык форматта булырга тиеш (кәгазь чыганакта урнаштыру чыганагына гиперсылтама күрсәтелә яисә электрон файл җайланмасы теркәлә) һәм шифрланмаган яисә махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән сакланмаган булырга тиеш.

Оешма заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда оешма заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яки заявканы кире алу оешма тарафыннан әлеге Тәртиптә билгеләнгән заявка формалаштыру тәртибендәге кебек тртиптә оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Сайлап алу Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Заявкаларны сайлап алуны үткәрү сроклары, кабул итү сроклары, заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты Министрлык боерыгы белән раслана.

Министрлык, заявкалар бирә башлау датасына кадәр биш календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштыруны тәэмин итә, анда түбәндәгеләр турында мәгълүмат күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы һәм вакыты, шул ук вакытта заявкаларны кабул итүнең тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган биш календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 16 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр

күрсәткечләре;

әлеге Кагыйдәләрнең 7 пункты нигезендә оешмаларга карата таләпләр һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен оешмалар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

сайлап алу критерийлары;

заявкаларны бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Тәртипнең 10 – 12 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

заявкаларны эшләп бетерү өчен кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук аларны кабул итмәү нигезләре;

сайлап алу кысаларында бүленә торган грант күләме, грант күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуда җиңүчегә бирелә торган грантның максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча грантны бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан грант бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) тиешле имза кую срогы;

сайлап алуны үткәрүне туктату тәртибе һәм очраклары, сайлап алу йомгаклары буенча килешүләр төзү очраклары һәм сайлап алу үткәрелмәгән дип тану очраклары;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыру сроклары (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмый).

Министрлык, табигый яисә техноген һәлакәтләр, хәрби хәрәкәтләр, Министрлык тарафыннан гадәттән тыш дип танылган башка хәлләр белән бәйле рәвештә барлыкка килгән, җиңеп булмый торган вакыйгалар килеп чыккан очракта, сайлап алуны уздырмый.

Министрлык тарафыннан бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуны уздырмау турында белдерүне урнаштыру заявкалар бирү срогы тәмамланган датага кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә. Сайлап алуны уздырмау турында белдерүгә Министрлык җитәкчесе тарафыннан кул куела, бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм сайлап алуны уздырмау сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Сайлап алу, бердәм порталда сайлап алуны үткәрмәү турында белдерү урнаштырылган көннән алып, уздырылмаячак дип санала.

Сайлап алуны уздырмау срогы тәмамланганнан соң һәм грант алучы белән килешү төзегәнгә кадәр Министрлык Россия Федерациясе Граждан кодексының 401

статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмаслык вакыйгалар барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны уздырмаска мөмкин.

10. Министрлыкка кергән заявка керү датасына һәм вакытына карап чират буенча кергән көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә. Заявка биргән оешманың вәкаләтле вәкиленә, аны алу датасын һәм вакытын күрсәтеп, Министрлыкның заявка алган вазыйфаи заты имзасы белән заявка алу турында расписка бирелә.

Заявка почта элемтәсен оештыру аша кергәндә, заявканы теркәү датасы дип Министрлыкка почта җибәрүләрен турыдан-туры бирү белән шөгыльләнүче почта элемтәсен оештыруның структур бүлекчәсе тарафыннан почта аша җибәрү датасы һәм вакыты санала, һәм алар почта юлламасында почта элемтәсен оештыруның тиешле структур бүлекчәсе штемпеле белән раслана.

Заявкалар Министрлыкның урнашу урыны адресы буенча карап тикшерелә. Бер оешма бер генә заявка бирергә мөмкин.

11. Заявкаларны карап тикшерү максатларында Министрлык тарафыннан заявкаларны карап тикшерү комиссиясе (алга таба – комиссия) төзелә. Комиссия Министрлык каршында кимендә биш әгъза (рәисне кертеп) составында Министрлык хезмәткәрләре, иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан төзелә.

Комиссиянең составы, аның эш тәртибе Министрлык боерыгы белән раслана.

Комиссия эше утырышларда башкарыла. Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссия заявкаларны кабул итү срогы чыккан көннән соң килә торган көннән алып өч календарь көннән дә соңга калмыйча:

заявкаларны, аларның керү чиратына карап, шулай ук оешманың әлеге Тәртипнең 6 һәм 7 пунктларында билгеләнгән сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килү-килмәвенә тикшерә;

сайлап алуда җиңүчене билгеләү турында карар кабул итә, ул Комиссия утырышы үткәрелгән көндә беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аңа Комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имза куела.

Сайлап алуда җиңүче дип әлеге Тәртипнең 6 һәм 7 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм сайлап алу критерийларына туры килә торган, заявкасы чират буенча беренче тапшырылган оешма таныла.

Комиссия карарлары Комиссия утырышында катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия утырышының беркетмәсе аңа имза куелган көнне Министрлыкка җибәрелә.

Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

оешманың әлеге Тәртипнең 6 һәм 7 пунктларында билгеләнгән сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

оешма тарафыннан бирелгән заявканың һәм (яки) документларның сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатларында,

оешма тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

оешма тарафыннан заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң заявка бирелү.

Заявка аларны карау стадиясендә кире кагылган очракта, Министрлык заявкаларны бирү сроклары тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә оешмага бу хакта хәбәр җибәрә.

12. Министрлык Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә грант бирү турында карар кабул итә һәм аны, Комиссия утырышы беркетмәсенә кул куелган көннән өч календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән раслый.

13. Министрлык, грант бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәгеләрне үз эченә ала торган сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән оешмалар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән оешмалар турында мәгълүмат (аларны кабул итмәү сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрне күрсәтеп);

килешү төзелә торган грант алучының исеме һәм аңа бирелә торган грантның күләме.

14. Грантның күләме 50,0 млн.сум тәшкил итә.

Сайлап алу йомгаклары буенча грант бер алучыга гына бирелә.

15. Грант аны алучының чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә бирелә.

Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнар юнәлешләре:

заявка бирү датасына оешманың креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыруны башкаручы персоналның хезмәте өчен түләү;

креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә төзелә торган кайтартулар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү, шул исәптән элемтә хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, бүлмәләрне арендалау, мөлкәтне карап тоту хезмәтләре шартнамәләре һәм башка шартнамәләр буенча түләү;

креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә исәпләнгән салымнарны түләү.

16. Грант бирү нәтиҗәләре:

«Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр уздыруга, квалификацияле кадрлар әзерләүгә һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерүгә юнәлдерелгән һәм гамәлгә ашырылган проектлар – кимендә 2;

генератив график нейрон челтәрләр маркетплейсларын анализлау нәтиҗәләре буенча иң уңышлы чишелешләрнең модельләрен төзеп, конкурентларны анализлау өчен ясалма интеллект кертеп эшләнгән платформа – кимендә 1;

мәдәният һәм креатив индустрияләр өлкәсендә проектларны инкубацияләүне һәм акселерацияләүне уздыру, лекцияләр, вебинарлар һәм семинарлар уздыру, материаллар урнаштыру һәм белемнәрне, компьютер күзләре һәм ясалма интеллект белән бурычларның үтәлешен тикшереп тору технологиясен кулланып, тестлар һәм биремнәр ярдәмендә тикшерү, оешманың кирәкле ИТ-инфраструктурасын модернизацияләү мөмкинлеге белән гамәлгә ашырылган уку-укыту платформасы – кимендә 1;

тематик фиджитал-турнирлар үткәрү өчен милли уеннар буенча виртуаль чынбарлыкның программа-аппарат комплексын эшләп, Россия халыкларының халык-сәнгать мәдәниятен өйрәнү нигезендә яңа үрнәктә эшләнгән фиджитал-уен – кимендә 1;

Россия халыкларының халык-сәнгать мәдәнияте үрнәкләренең нәшер ителгән җыентыклары – кимендә 50;

мәдәнияттә һәм креатив индустрияләрдә цифрлы технологияләр өлкәсендә интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен хокукый яктан саклау – кимендә 2;

Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгы каршындагы Югары аттестация комиссиясе рецензияләгән фәнни-тикшеренү журналларында мәдәният, цифрлы технологияләр һәм креатив индустрияләрдә технологик эшкуарлык өлкәләрендә фәнни мәкаләләр бастырып чыгару – кимендә 20;

мәдәният, цифрлы технологияләр һәм креатив индустрияләрдә технологик эшкуарлык өлкәләрендә Scopus мәгълүматлар базаларында индексацияләнә торган фәнни мәкаләләр бастырып чыгару – кимендә 1;

креатив индустриядә нәшер ителгән монографияләр – кимендә 2;

мәдәният, цифрлы технологияләр һәм креатив индустрияләрдә технологик эшкуарлык өлкәләрендә нәшер ителгән уку ярдәмлекләре, методик тәкъдимнамәләр, нота басмалары, конференцияләр җыентыклары, альбом китап – кимендә 1;

мәдәният, цифрлы технологияләр һәм креатив индустрияләр өлкәләрендә халыкара фәнни конференцияләр мәкаләләренең нәшер ителгән җыентыклары – кимендә 3;

махсус программа-аппарат комплексын кулланып һәм штатта музыка буенча квалификацияле дипломлы белгечләр булдырып, белем бирүнең барлык дәрәҗәләрендә катнашучыларны, шулай ук киң катлам халыкны музыка чаралары белән психоэмоциональ тернәкләндерү һәм социаль җайлашу эшчәнлеге өчен фәнара тикшеренүләрнең фәнни-эксперименталь лабораториясен ачу – кимендә 1;

киемнең эшләнгән һәм федераль һәм халыкара базарларга чыгарылган бренды – кимендә 1;

киемнәрнең эшләнгән коллекцияләре – кимендә 2;

мода һәм дизайнның югары мәктәп-студиясе шоурумының эшләнгән дизайн-проекты – кимендә 1.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә субсидия бирелгән елның 31 декабренә кадәр ирешелергә тиеш.

17. Грант бирү өчен нигез – Министрлык белән грант алучы арасында әлеге Тәртипнең 13 пункты нигезендә Министрлык тарафыннан сайлап алуга йомгаклар ясау турында беркетмә урнаштырылган көннән соң килә торган биш эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең типовой формасы нигезендә төзелә торган килешү.

Кирәк булганда Министрлык белән грант алучы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзелә.

18. Килешүгә түбәндәге нигезләмәләр кертелә:

грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә грант алучының ризалыгы;

грант алучы, шулай ук грант алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела.

килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт.

19. Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә грант алучы үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Грант алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук грант алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, грант алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган йөкләмәләр һәм грантның файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

20. Грант, Министрлык тарафыннан грант бирү турында карар кабул ителгән

көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яки кредит оешмасында субсидия алучы тарафыннан ачылган субсидия алучының исәп-хисап яки корреспондентлык счетына күчерелә.

21. Грант алучы хисап кварталыннан соң килә торган айның 15нче көненә кадәр, шулай ук хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча грант бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап кертә.

Министрлык килешүдә өстәмә хисап бирү срокларын һәм формаларын билгеләргә хокуклы (кирәк булганда).

22. Министрлык кергән хисапларны Министрлыкка кергән датадан бер эш көне эчендә терки, хисаплар теркәлгән датадан алып 15 календарь көн эчендә грант алучы тарафыннан бирелгән хисапларны тикшерүне гамәлгә ашыра.

23. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган акчаның хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Министрлык тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган акчаны әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга тоту ихтыяҗы булган очракта, грант алучы Министрлыкка, хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, грант алучыдан әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, агымдагы финанс елында хисап финанс елында грантның файдаланылмый калган өлешен тотуга ихтыяҗ булу яисә булмау турында карар кабул итә.

Министрлык тарафыннан агымдагы финанс елында грантның хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен тотуга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык һәм грант алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча килешүгә өстәмә килешү төзелә.

24. Министрлык грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен, шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Министрлык килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешүне һәм грант бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглауны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглау тәртибендә каралган тәртиптә һәм формалар буенча уздыра.

25. Грант алучы тарафыннан грант бирү шартлары һәм тәртибе бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган очракта, шулай ук әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән грант бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән очракта, грант алучы алынган акчаны Министрлыкның язма таләбен алган көннән 30 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

26. Әлеге Тәртипнең 23 һәм 25 пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, Министрлык грант алучының алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарудан баш тарту турындагы хәбәрен алган көннән яки грант алучы алган һәм вәкаләтле органның язма таләбендә күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары нигезендә ирекле рәвештә кире кайтару вакыты чыкканнан соң календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

27. Грантны нәтиҗәле файдалануны, аны бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү өчен югары белем бирү мәгариф оешмасына субсидия рәвешендә грант бирү тәртибенә кушымта

Форма

Теркәү номеры:
Заявканы теркәү датасы:

Креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү өчен югары белем бирү мәгариф оешмасына субсидия рәвешендә грант бирүгә сайлап алуда катнашуга
заявка

20__ ел, «___» ___________

1. Югары белем бирү мәгариф оешмасының тулы исеме:
______________________________________________________________________

2. Югары белем бирү мәгариф оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек максатлары һәм төрләре турында мәгълүмат: ____________________________

3. Грантның исеме: ____________________________________________________

4. Грантның суммасы: __________________________________________________

5. Югары белем бирү мәгариф оешмасының урнашу урыны: _________________
______________________________________________________________________

6. Грантны күчерү өчен югары белем бирү мәгариф оешмасының банк реквизитлары: ________________________________________________________

Әлеге заявка белән югары белем бирү мәгариф оешмасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру

мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерциялəштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү өчен югары белем бирү мәгариф оешмасына субсидия рәвешендә грант бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 15 ноябрь, 1013 нче карары белән расланган Креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерциялəштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү өчен югары белем бирү мәгариф оешмасына субсидия рәвешендә грант бирү тәртибенең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый.

Әлеге заявка белән югары белем бирү оешмасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә югары белем бирү мәгариф оешмасы турында, югары белем бирү мәгариф оешмасы тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, грант бирүгә тиешле сайлап алуга бәйле югары белем бирү мәгариф оешмасы турында башка мәгълүмат турында мәгълүмат бастыруга (урнаштыруга) ризалыгын раслый.

Кушымталар: 1.
2.

Заявка бирүче ______________________________/ _________________________/___________
(югары белем бирү мәгариф оешмасы исеме) (җитәкченең фамилиясе, инициаллары) (имза)
)

________________________________